| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 марта 2025 г. с.Шалты № 117

Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының «Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы районы территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын билгеләү турында» 20.01.2025 ел, № 1 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрнең атамалары турында» 25.12.2024 ел, №10/13-09/6137 хаты нигезендә Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының «Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына (17.04.2020 № 115, 18.12.2020 № 11, 06.06.2024 № 98, 28.10.2024 № 107 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кыскартылган атамасы - Шалты авыл җирлеге.»;

31 статьяның 1 пунктында «10 депутат» санын һәм сүзләрен «7 депутат» сүзләренә һәм санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен Юстиция органына җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлешендә каралган тәртиптә үз көченә керә торган әлеге карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 20.03.2025 № 116 «Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының «Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 17.10.2019 № 96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин